ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ**

___________18.09.2023_____ №___125-од__________

г. Казань

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең эш урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты комиссиясе турында**

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында» 2010 елның 01 июлендәге 821 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында» 2010 елның 25 августындагы 569-ПУ номерлы Указы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең эш урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча

Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты комиссиясе турында нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең эш урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты комиссиясе составын расларга.

3. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының түбәндәге боерыкларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең эш урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты комиссиясе турында» 2017 елның 18 гыйнварындагы 006-од номерлы;

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең эш урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 29 мартындагы 38-од номерлы;

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең эш урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 28 сентябрендәге 137-од номерлы.

**Рәис** **Г. З. Габдрахманова**

Татарстан Республикасының Архив
эше буенча дәүләт комитетының
_______2023____ел, _
125-од________номерлы боерыгы
белән расланды

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең эш урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты комиссиясе турында нигезләмә

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең эш урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты комиссиясе турында нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең эш урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында» 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Указы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең эш урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турында» 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Указы нигезендә эшләнде. Нигезләмәдә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең эш урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан

Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты комиссиясен (алга таба - Комиссия) төзү һәм аның эшчәнлеге тәртибе билгеләнә.

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Комиссиянең төп бурычы - түбәндәгеләргә ярдәм итү:

а) Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба - дәүләт хезмәткәрләре) тарафыннан чикләүләр һәм тыюларның, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлүен тәэмин итүдә, шулай ук алар тарафыннан «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда билгеләнгән бурычларның (алга таба - эш урынындагы тәртипкә карата таләпләр һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләр) үтәлүен тәэмин итүдә;

б) Дәүләт комитетында коррупцияне кисәтү чараларын гамәлгә ашыруда.

1.4. Комиссия Дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын (алга таба - дәүләт хезмәте вазыйфаларын) биләүче дәүләт хезмәткәрләренә карата (дәүләт хезмәте вазыйфаларына билгеләп кую һәм алардан азат итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан башкарыла торган дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләреннән тыш) эш урынындагы тәртипкә карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлешенә бәйле мәсьәләләрне карый.

1.5. Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазыйфаларына билгеләп кую һәм алардан азат итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан башкарыла торган дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләренең эш урынындагы тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлешенә бәйле мәсьәләләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында төзелгән эш урынындагы

тәртипкә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе тарафыннан карала.

1.6. Комиссия җинаятьләр һәм административ хокук бозулар турындагы хәбәрләрне, шулай ук аноним мөрәҗәгатьләрне карамый, хезмәт дисциплинасын бозу фактлары буенча тикшерүләр уздырмый.

## II. Комиссия составы

2.1. Комиссия составына Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче Комиссия әгъзалары арасыннан Дәүләт комитеты рәисе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба - Дәүләт комитеты рәисе) тарафыннан билгеләп куела торган Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, секретарь һәм комиссия әгъзалары керә. Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукка ия. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

2.2. Комиссия составына түбәндәгеләр керә:

а) Дәүләт комитеты рәисе урынбасары (Комиссия рәисе), Дәүләт комитеты рәисе урынбасары (Комиссия рәисе урынбасары), Дәүләт комитетының хокук һәм кадрлар эшенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты, рәис карары нигезендә Дәүләт комитетының башка бүлекчәләре вәкилләре;

б) Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Рәисе идарәсе һәм (яисә) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәсе вәкиле;

в) эшчәнлеге дәүләт хезмәте белән бәйле булган фәнни оешмалар, һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирү мәгариф оешмалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары вәкиле (вәкилләре).

2.3. Дәүләт комитеты рәисе Комиссия составына Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет вәкилен, Дәүләт комитетының беренчел һөнәри берлек оешмасын кертү турында карар кабул итәргә мөмкин.

2.4. Әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктындагы «б» һәм «в» пунктчаларында һәм 2.3 пунктында күрсәтелгән затлар Комиссия составына Дәүләт комитеты рәисе соратуы нигезендә тиешле органнар һәм оешмалар белән килештерелгәннән соң кертелә.

2.5. Комиссиянең Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазыйфасын биләмәүче әгъзалары саны Комиссия әгъзаларының гомуми санынннан кимендә дүрттән берен тәшкил итәргә тиеш.

2.6. Комиссия составы Комиссия кабул итә торган карарга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү ихтималын булдырмаслык итеп төзелә.

2.7. Комиссия утырышларында киңәш бирү тавышы хокукына ия түбәндәгеләр катнаша:

а) Комиссия тарафыннан эш урынындагы тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлеше турындагы мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе һәм Комиссия тарафыннан бу мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәре биләгән вазыйфага Дәүләт комитетында туры килә торган дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче ике дәүләт хезмәткәре, аларны Комиссия рәисе билгели;

б) Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче башка дәүләт хезмәткәрләре; дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм Комиссия карый торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирә алучы белгечләр; башка дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары; мәнфәгатьле оешмалар вәкилләре; Комиссия тарафыннан эш урынындагы тәртипкә карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлеше турындагы мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәре вәкиле - Комиссия утырышына кадәр кимендә өч көн кала һәр очрак өчен, Комиссия тарафыннан бу мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәре яисә Комиссиянең теләсә кайсы әгъзасы үтенечнамәсенә нигезләнеп, аерым кабул ителә торган Комиссия рәисе карары буенча.

2.8. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала. Дәүләт комитетында дәүләт

хезмәте вазыйфаларын биләүче комиссия әгъзалары катнашында гына утырышлар үткәрү рөхсәт ителми.

2.9. Комиссия әгъзасының Комиссия утырышы көн тәртибенә кертелгән мәсьәләне караганда мәнфәгатьләр конфликтына китерергә мөмкин турыдан-туры яисә читләтелгән шәхси мәнфәгате барлыкка килгәндә, ул утырыш башланганчы бу турыда хәбәр итәргә тиеш. Мондый очракта Комиссиянең тиешле әгъзасы күрсәтелгән мәсьәләне карауда катнашмый.

## III. Комиссиянең эш тәртибе

3.1. Комиссия утырышын уздыру өчен түбәндәгеләр нигез була:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын һәм дәүләт хезмәткәре тарафыннан эш урынындагы тәртипкә карата таләпләрнең үтәлешен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә уздырылган тикшерү нәтиҗәләре буенча Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан түбәндәгеләрне раслый торган тикшерү материаллары тапшырылу:

Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында нигезләмәдә каралган белешмәләрнең дәүләт хезмәткәре тарафыннан дөрес яисә тулысынча тапшырылмавы турында белешмәләр тапшыру хакында;

дәүләт хезмәткәрләренең эш урынындагы тәртибенә һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәве турында;

б) коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы Дәүләт комитетының хокук һәм кадрлар эше бүлегенең вазыйфаи затына Дәүләт комитеты боерыгында билгеләнгән тәртиптә кергән:

Дәүләт комитеты боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә кертелгән дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан, коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмада вазыйфа биләүгә йә коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эш башкаруга ризалык бирү турында, әгәр бу оешмага дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, дәүләт хезмәтеннән азат ителгән көннән алып ике ел узганчы;

дәүләт хезмәткәренең объектив сәбәпләр буенча хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру мөмкинлеге булмау турында гаризасы;

“Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлар (кертемнәр) булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында” 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәүнең территориясендә счетлар (кертемнәр) булган, чит ил банкларында нал акча чаралары һәм кыйммәтләр саклана торган һәм чит ил финанс кораллары булган чит ил дәүләте законнары нигезендә чит ил компетентлы органнары карары белән кулга алыну, тыю кертелүгә бәйле рәвештә яисә аның ихтыярына яки аның хатыны (ире) ихтыярына бәйле булмаган башка шартлар аркасында мөмкин булмавы турында дәүләт хезмәткәре гаризасы;

вазыйфаи бурычны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында дәүләт хезмәткәренең хәбәр итүе;

в) Дәүләт комитеты рәисенең яисә Комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының дәүләт хезмәткәренең эш урынындагы тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлешен тәэмин итүгә йә Дәүләт комитетында коррупцияне кисәтү чараларын башкаруга кагылышлы белешмә тапшыруы;

г) «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган белешмәләрнең дәүләт хезмәткәре тарафыннан дөрес яисә тулы булмаганрәвештә тапшырылуы турында таныклый торган тикшерү материалларының Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан тапшырылуы;

д) “Коррупциягә каршы көрәш турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясындагы 4 өлеше һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 64[1]статьясы нигезендә Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан белән эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт яисә гражданлык-хокук шартнамәсе төзелү турында коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешманың хәбәр итүе, әгәр әлеге оешманың дәүләт идарәсенең аерым функцияләре аның Дәүләт комитетында вазыйфа биләгән вакытта башкарган вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, күрсәтелгән гражданга Комиссия элегрәк әлеге оешма белән хезмәт һәм гражданлык-хокук мөнәсәбәтләренә керүдә рөхсәт бирелмәгән очракта яисә мондый гражданга коммерциячел яки коммерциягә карамаган оешмада вазыйфа биләвенә йә гражданлык-хокук шартнамәсе шартларында эш башкаруына рөхсәт бирү турында мәсьәлә Комиссия тарафыннан каралмаган булса.

3.2. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан тарафыннан Дәүләт комитетының хокук һәм кадрлар эше бүлегенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затына тапшырыла. Мөрәҗәгатьтә түбәндәгеләр күрсәтелә: гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) аның туу датасы,

яшәү урыны адресы, дәүләт хезмәтеннән азат ителгән көнгә кадәр соңгы ике ел дәвамында биләгән вазыйфалары, коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешманың исеме, урнашу урыны, аның эшчәнлеге төре, дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән вакытта граждан башкарган вазыйфаи (хезмәт) вазыйфалары, коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмага дәүләт идарәсе функцияләре, шартнамәнең төре (хезмәт яисә гражданлык-хокук), аның күз алдында тотылган гамәлдә булу срогы, шартнамә буенча эшләр (хезмәтләр) башкару (хезмәтләр күрсәтү) өчен түләү суммасы. Дәүләт комитетының хокукый һәм кадрлар эше бүлегенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты “Коррупциягә каршы көрәш турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы таләпләрен исәпкә алып мөрәҗәгать итүнең асылы буенча анықланган бәяләмә әзерли торган мөрәҗәгатьне карый.

3.3. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне дәүләт хезмәтеннән китәргә җыенучы дәүләт хезмәткәрләре тапшырырга мөмкин, һәм ул Комиссия тарафыннан әлеге Нигезләмәгә таянып каралырга тиеш.

3.4. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамә Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан тарафыннан «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы таләпләре үтәлү турында анықланган бәяләмә әзерләүче Дәүләт комитетының хокук һәм кадрлар эше бүлегенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан карала.

3.4.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән хәбәрнамә хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча анықланган бәяләмә әзерләүче Дәүләт комитетының хокук һәм кадрлар эше бүлегенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан карала.

3.4.2. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча анықланган

бәяләмәне яисә әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәләрне әзерләгәндә Дәүләт комитетының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты мөрәҗәгатьне яисә хәбәрнамәне тапшырган дәүләт хезмәткәре белән әңгәмә уздырырга, аннан язма аңлатмалар алырга хокуклы. Мәгълүмат алу өчен Дәүләт комитеты дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, һәм мәнфәгатьле оешмаларга соратулар җибәрә ала, «Посейдон» коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасын, шул исәптән соратулар җибәрү өчен, кулланырга мөмкин. Мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә алынган көннән алып җиде эш көне эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Соратулар юлланган очракта мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә кергән көннән алып 45 көн эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән дә артыкка түгел.

3.4.3 Әлеге Нигезләмәнең 3.2, 3.4, 3.4.1 пунктларында каралган анықланган бәяләмәләрдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яисә хәбәрнамәләрдә бәян ителгән мәгълүмат;

б) соратулар нигезендә дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм мәнфәгатьле оешмалардан алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктларындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм хәбәрнамәләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча анықланган нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.13, 3.15.1, 3.18 пунктлары нигезендә карарларның берсен яисә башка карарда кабул итү өчен тәкъдимнәр.

3.5. Комиссия рәисе Комиссия утырышын үткәрү өчен нигез булган мәгълүмат кергәндә:

а) 10 көн эчендә Комиссия утырышы датасын билгели. Бу вакытта Комиссия утырышы датасы, әлеге Нигезләмәнең 3.6 һәм 3.7 пунктларында каралган

очраклардан тыш, күрсәтелгән мәгълүмат кергән көннән 20 көннән дә соңга калып билгеләнә алмый;

б) Комиссия тарафыннан эш урынындагы тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлеше турындагы мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәрен, аның вәкилен, Комиссия әгъзаларын һәм Комиссия утырышында катнашучы башка затларны Дәүләт комитетының хокук һәм кадрлар эше бүлегенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затына килгән мәгълүмат белән һәм аны тикшерү нәтиҗәләре белән танышутыруны оештыра;

в) Комиссия утырышына әлеге Нигезләмәнең 2.7 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән затларны чакыру турындагы үтенечнамәне карый, аларны канәгатьләндерү (канәгатьләндерүдән баш тарту) һәм Комиссия утырышы барышында өстәмә материаллар карау (караудан баш тарту) турында карар кабул итә.

3.6. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән гаризаларны карау комиссиясе утырышы керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән срок тәмамланган көннән алып бер айдан да соңга калмыйча уздырыла.

3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамә Комиссиянең чираттагы (план буенча) утырышында карала.

3.8. Комиссия утырышы эш урынындагы тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлеше турындагы мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәре яисә Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан катнашында уздырыла. Дәүләт хезмәткәре яисә граждан Комиссия утырышында шәхсән үзе катнашу теләге булу турында әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә тапшырыла торган мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә хәбәрнамәдә күрсәтә.

3.8.1. Комиссия утырышлары дәүләт хезмәткәре яисә граждан булмаганда түбәндәге очракларда үткәрелергә мөмкин:

а) әгәр әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасында каралган мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә хәбәрнамәдә дәүләт хезмәткәренең яисә гражданның Комиссия утырышында шәхсән катнашырга уйлавы турында белдерелмәсә;

б) әгәр Комиссия утырышында шәхсән үзе катнашырга теләгән һәм аның үткәрелү вакыты һәм урыны турында тиешенчә хәбәрдар дәүләт хезмәткәре яисә граждан Комиссия утырышына килмәсә.

3.9. Комиссия утырышында Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән дәүләт хезмәткәренең яисә гражданның (аларның ризалыгы белән) һәм башка затларның аңлатмалары тыңлана, әлеге утырышка чыгарылган сорауларның асылы буенча материаллар, шулай ук өстәмә материаллар карала.

3.10. Комиссия әгъзалары һәм аның утырышында катнашкан затлар Комиссия эше барышында аларга мәгълүм булган мәгълүматларны фаш итәргә хокуксыз.

3.11. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «а» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында нигезләмәгә таянып тапшырылган белешмәләр дөрес һәм тулы дип билгеләргә;

б) дәүләт хезмәткәре тарафыннан әлеге пунктның «а» пунктчасында аталган Нигезләмәгә таянып тапшырылган белешмәләрнең дөрес түгел һәм (яисә) тулы түгел дип билгеләргә. Бу очракта Комиссия Дәүләт комитеты рәисенә дәүләт хезмәткәренә карата тәгәл җаваплылык чарасын кулланырга киңәш итә.

3.12. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «а» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре эш урынындагы тәртипкә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәгән дип билгеләргә;

б) дәүләт хезмәткәре эш урынындагы тәртипкә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән дип билгеләргә. Бу очракта Комиссия Дәүләт комитеты рәисенә дәүләт хезмәткәренә эш урынындагы тәртипкә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне бозуның ярамаганлыгын күрсәтергә йә дәүләт хезмәткәренә карата төгәл җаваплылык чарасын кулланырга киңәш итә.

3.13. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) гражданга коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмада вазыйфа биләүгә йә, әгәр бу оешмага дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмада гражданлык-хокук шартнамәсе шартларында эш башкаруга рөхсәт бирү;

б) гражданга коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмада вазыйфа биләүдән йә, әгәр бу оешмага дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмада гражданлык-хокук шартнамәсе шартларында эш башкарудан баш тарту һәм баш тартуны дәлилләү.

3.14. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырылмау сәбәбен объектив һәм нигезле дип танырга;

б) дәүләт хезмәткәре тарафыннан хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырылмау сәбәбен нигезле түгел дип танырга. Бу очракта Комиссия

дәүләт хезмәткәренә күрсәтелгән белешмәләрне тапшыру буенча чаралар күрергә тәкъдим итә;

в) дәүләт хезмәткәре тарафыннан хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырылмау сәбәбен объектив түгел һәм күрсәтелгән белешмәләрне тапшырудан баш тарту ысулы булып тора дип танырга. Бу очракта Комиссия Дәүләт комитеты рәисенә дәүләт хезмәткәренә карата тәгәл җаваплылык чарасын тикшерергә тәкъдим итә.

3.15. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының дүртенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) "Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулый торган шартларның объектив һәм нигезле булуын танырга;

б) «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулый торган шартларны объектив һәм нигезле түгел дип танырга. Бу очракта Комиссия Дәүләт комитеты рәисенә дәүләт хезмәткәренә карата тәгәл җаваплылык чарасын тикшерергә тәкъдим итә.

3.15.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликты булмавын танырга;

б) дәүләт хезмәткәре вазыйфаи бурычларын үтәгәндә шәхси мәнфәгатьләре булуның мәнфәгатьләр конфликтына китерүен яисә китерергә мөмкин булуын танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә һәм (яисә) Дәүләт комитеты рәисенә мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу яки аның барлыкка килүен булдырмау буенча чаралар күрергә тәкъдим итә;

в) дәүләт хезмәткәре мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән дип танырга. Бу очракта Комиссия Дәүләт комитеты рәисенә дәүләт хезмәткәренә карата тәгәл җаваплылык чарасын кулланырга киңәш итә.

3.16. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «в» пунктчасында каралган мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия тиешле карар кабул итә.

3.17. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «г» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә нисбәтен тикшереп тору турында» Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлеше нигезендә тапшырылган белешмәләрне дөрес һәм тулы дип танырга;

б) дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә нисбәтен тикшереп тору турында» Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлеше нигезендә тапшырылган белешмәләрне дөреслеккә туры килми һәм (яисә) тулы түгел дип танырга. Бу очракта Комиссия Дәүләт комитеты рәисенә дәүләт хезмәткәренә карата җаваплылыкның төгәл чарасын кулланырга һәм (яисә) чыгымнарны тикшереп тору нәтиҗәсендә алынган материалларны үз компетенцияләре нигезендә прокуратура органнарына һәм (яисә) башка дәүләт органнарына җибәрергә киңәш итә.

3.18. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданга карата түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмада аңа вазыйфа биләргә йә коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмада гражданлык-хокук

шартнамәсе шартларында эш башкарырга, әгәр бу оешмага дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, рөхсәт итәргә;

б) коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмада хезмәт шартнамәсе шартларында вазыйфа биләү һәм (яисә) коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешмада эшләр башкару (хезмәтләр күрсәтү) «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы таләпләрен боза дип билгеләргә. Бу очракта Комиссия Дәүләт комитеты рәисенә күрсәтелгән шартлар турында прокуратура органнарына һәм хәбәр иткән оешмага мәгълүмат бирергә тәкъдим итә.

3.19. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “а”, “б”, “г” һәм “д” пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия, әгәр нигезләр булса, әлеге Нигезләмәнең 3.11 - 3.15.1, 3.17 - 3.18 пунктларында каралган карарлардан тыш башка карар кабул итәргә мөмкин. Мондый карарны кабул итүнең нигезләре һәм сәбәпләре Комиссия утырышы беркетмәсендә күрсәтелергә тиеш.

3.20. Комиссия карарларын үтәү өчен Дәүләт комитетының норматив хокукый актлары, Дәүләт комитеты рәисе карарлары яисә күрсәтмәләре проектлары әзерләнергә мөмкин, алар билгеләнгән тәртиптә Дәүләт комитеты рәисе каравына тапшырыла.

3.21. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча Комиссия карарлары яшерен тавыш бирү юлы белән (әгәр Комиссия башка карар кабул итмәсә) Комиссия утырышында катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

3.22. Комиссия карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларга Комиссия утырышында катнашкан әгъзалар имза сала. Комиссия карарлары, әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карардан тыш, Дәүләт комитеты рәисенә тәкъдим рәвешендә була. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карар мәҗбүри була.

3.23. Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) Комиссия утырышы датасы, Комиссия утырышында катнашучы әгъзаларның һәм башка затларның фамилияләре, исемнәре, атасының исеме (булган очракта);

б) Комиссия утырышында карала торган мәсьәләләрнең һәркайсын, эш урынындагы тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлеше турындагы мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәренең фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта), вазыйфасын күрсәтеп, билгеләп кую;

в) дәүләт хезмәткәренә карата белдерелә торган дәгъвалар, алар нигезләнгән материаллар;

г) белдерелә торган дәгъваларның асылы буенча дәүләт хезмәткәре һәм башка затлар аңлатмаларының эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилияләре, исемнәре, атасының исеме (булган очракта);

е) Комиссия утырышын уздыру өчен нигез булган мәгълүмат чыганагы, Дәүләт комитетына мәгълүмат керү датасы;

ж) башка белешмәләр;

з) тавыш бирү нәтиҗәләре;

и) карары һәм аны кабул итү өчен нигез.

3.24. Комиссия карары белән килешмгән аның әгъзасы үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, ул Комиссия утырышы беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә теркәп куелырга тиеш һәм аның белән дәүләт хезмәткәре танышырга тиеш.

3.25. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәләре утырыш булган көннән алып 7 көн эчендә Дәүләт комитеты рәисенә, тулысынча яисә аннан өземтә рәвешендә - дәүләт хезмәткәренә, шулай ук Комиссия карары буенча - башка мәнфәгатьле затларга җибәрелә.

3.26. Дәүләт комитеты рәисе Комиссия утырышы беркетмәсен карарга тиеш һәм дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул иткәндә үз

компетенциясе чикләрендә, шулай ук коррупциягә каршы торуны оештыруның башка мәсьәләләре буенча тәкъдимнәрне исәпкә алырга хокуклы. Рәис Комиссия тәкъдимнәрен карау һәм кабул ителгән карар турында Комиссиягә Комиссия утырышы беркетмәсе кергән көннән алып бер ай эчендә хәбәр итә. Рәис карары Комиссиянең якындагы утырышында игълан ителә һәм фикер алышмыйча гына игътибарга алына.

3.27. Дәүләт хезмәткәре гамәлләрендә (гамәл кылмавында) дисциплинар гаеп гамәл билгеләре булу Комиссиясе тарафыннан ачыкланган очракта, бу хакта мәгълүмат дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын куллану турындагы мәсьәләне хәл итү өчен Дәүләт комитеты рәисенә тапшырыла.

3.28. Комиссия административ хокук бозу яисә җинаять составы билгеләрен үз эченә алган гамәл кылу факты (гамәл кылмау факты) булуны билгеләгән очракта, Комиссия рәисе күрсәтелгән гамәлне кылу (гамәл кылмау) турында мәгълүматны һәм мондый фактның булуын раслый торган документларны хокук куллану органнарына 3 көн эчендә, ә кирәк булганда - кичекмәстән тапшырырга тиеш.

3.29. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе яисә аннан өземтә эш урынындагы тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлеше мәсьәләсе каралган дәүләт хезмәткәренең шәхси эшенә теркәлеп куела.

3.30. Комиссия секретареның имзасы һәм Дәүләт комитеты мөһере белән таныкланган Комиссия карарыннан өземтә Дәүләт комитетында дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәлә каралган гражданга кул куйдыртып тапшырыла яисә, шушы Комиссиянең тиешле утырышы үткәрелгән көннән соң килүче бер эш көненнән дә соңга калмыйча, аның тарафыннан мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән адреска алынуы турында хәбәр ителә торган заказлы хат белән юллана.

3.31. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан һәм документация белән тәэмин итү, шулай ук Комиссия әгъзаларына көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр турында, утырышны уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында хәбәр итү,

Комиссия әгъзаларын Комиссия утырышында фикер алышу өчен тәкъдим ителә торган материаллар белән таныштыру Дәүләт комитетының хокук һәм кадрлар эше бүлегенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан гамәлгә ашырыла.